ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422150

Яшьлек ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Карар Постановление

« 25» декабрь, 2025 ел. №34

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге

-2025 елның 28 нче октябрь 1 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 28 нче октябрь 2 нче санлы «Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Дүсмәт торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;

-2025 елның 28 нче октябрь 3 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Комазан Башы торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 28 нче октябрь 4 нче санлы «Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Комазан башы торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;

-2025 елның 28 нче октябрь 5 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Акман торак пунктында үзара салым кертү турында »;

-2025 елның 28 нче октябрь 6 нчы санлы «Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Акман торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»;

-2025 елның 28 нче октябрь 7 нче санлы « 2026 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Иске Комазан торак пунктында үзара салым кертү турында »;
-2025 елның 28 нче октябрь 8 нче санлы «Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Иске Комазан торак пунктында гражданнарның үзара салымны кертү һәм файдалану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» гы карарлар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Р.М.Ефимов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.12. 2025 ел, 34 нче санлы
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2026 елның 25 нче мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25 нче декабрь, 2025 ел,
34 нче санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш Муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
__________________________________________________________________________
______________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2026 нчы елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 25.03.2026 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ____сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: УФК по РТ (Финансово-бюджетная палата Мамадышского муниципального района РТ)
Кабул итүче як банкы
Сч. №
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН
КПП
КБК
ОКТМО
Түләүнең билгеләнеше: Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче _________________ ________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

_______________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ______________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________________
«__» _______________ 20__ г. _____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)___________________*
*авыл җирлеге Башкарма комитетында тотырыла һәм кала.*